**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АПАС ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАРЫ

2020 ел,14 декабрь № 106

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлегенең муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законның 46 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 9нчы ноябрендәге, № 363-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр тибындагы поселогы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында Нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 12 маендагы 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр тибындагы поселогы муниципаль норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3)Гадәттән тыш хәлләр режимнары гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен узем тикшереп торам.

**Апас шәһәр тибындагы поселогы**
**Башкарма комитет җитәкчесе** **Ф.Ә. Шәрәфетдинов**